ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

2024 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында
закон проекты эшенең якынча планы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Закон чыгару инициативасы хокукына ия субъектларга 2024 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планы нигезендә закон проектларын үз вакытында әзерләүне һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертүне тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының тиешле комитетлары эшчәнлеген җайга салучы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасарларына 2024 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планына кертелгән закон проектларын әзерләү срокларын үтәүне контрольдә тотарга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2023 елның 18 декабре
№ 2305-VI ДС

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советының
2023 елның 18 декабрендәге
2305-VI ДС номерлы
карарына кушымта

**2024 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планы**

| № т/б | Проектның исеме | Закон чыгару инициативасы хокукы субъекты | Проектны Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тәкъдим итү срогы |
|---|---|---|---|
| **1. Дәүләт корылышы** | | | |
| 1 | «Түбән Кама муниципаль районының «Түбән Кама шәһәре» һәм «Прости авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләренең территорияләре чикләрен үзгәртү турында һәм «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (Түбән Кама шәһәрендә «Биклән урманчылыгы» яңа торак пунктын (урман поселогын) булдыру максатыннан, шулай ук Түбән Кама шәһәре территориясенең бер өлешен Прости авыл җирлегенә тапшыру юлы белән Түбән Кама муниципаль | Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы советы | I квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | районының «Түбән Кама шәһәре» һәм «Прости авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләренең чикләрен үзгәртү максатыннан) | | |
| 2 | «Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 11 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты («Һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм коткаручыларның статусы турында» Федераль законның 10 статьясындагы 2 пункты нигезендә һәлакәттән коткару хезмәтләрен һәм һәлакәттән коткару формированиеләрен теркәүне гамәлгә ашыра торган органнарны төгәлләштерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты | II квартал |
| 3 | «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламенты турында» 2004 елның 26 февралендәге 2632 номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты (Татарстан Республикасы законнарына туры китерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты | II квартал |
| 4 | «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (муниципаль норматив хокукый актларга (муниципаль норматив хокукый актлар проектларына) экспертиза (җайга | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты | IV квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | салу йогынтысын бәяләү) үткәрү мәҗбүри булган муниципаль районнар һәм шәһәр округлары исемлеген төгәлләштерү максатыннан) | | |
| 5 | «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (күрсәтелгән закон актларының аерым нормаларын «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законгагы үзгәрешләргә туры китерү максатыннан) | Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе | IV квартал |
| **2. Икътисадый сәясәт** | | | |
| 6 | «Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты («Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга, әйләнә-тирә мохит торышының федераль мәгълүмат системасын булдыру һәм аның эшчәнлеге мәсьәләләрен җайга салу өлешендә, һәм «Табигый дәвалау ресурслары, дәвалау-савыктыру җирлекләре һәм курортлар турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга, рекреацион зоналар, табигый дәвалау ресурсларының | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты | I квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | санитар (тау-санитар) саклау округлары чикләрендә җитештерү һәм куллану калдыклары күмүне тыюга кагылышлы нигезләмәләрне төгәлләштерү өлешендә, туры китерү максатыннан) | | |
| 7 | «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты («Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законга, «торак пунктлар җирләре» төшенчәсен һәм «торак пунктлар чикләре» төшенчәсен билгеләү өлешендә, шулай ук «Табигый дәвалау ресурслары, дәвалау-савыктыру җирлекләре һәм курортлар турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга, «махсус сакланылучы территорияләр җирләре» төшенчәсен һәм әлеге җирләрнең составын билгеләү өлешендә, туры китерү максатыннан | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты | I квартал |
| 8 | «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 5 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (капиталь ремонтка кертемнәр түләү тәртибен төгәлләштерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Р.Х. Сөләйманов | I квартал |
| 9 | «2023 елгы Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында» Татарстан Республикасы законы проекты | Татарстан Республикасы Рәисе | II квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 10 | «2023 елгы Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турында» Татарстан Республикасы законы проекты | Татарстан Республикасы Рәисе | II квартал |
| 11 | «Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (ятим балаларның, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларның милек хокукындагы яисә алар тарафыннан «Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм итүнең өстәмә гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә торак урыннар белән тәэмин итү хокукын гамәлгә ашыру тәртибендә алынган индивидуаль торак төзелеше объектлары яисә блоклап төзелгән өйләр урнашкан дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен Россия Федерациясе Җир кодексының $39^5$ статьясындагы 7 пунктчасы нигезендә күрсәтелгән затларга милеккә түләүсез бирү хакында) | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты | II квартал |
| 12 | «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә башкарма хакимият органнары вәкаләтләрен төгәлләштерү максатыннан) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты | II квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 13 | «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (кече һәм урта эшкуарлык субъектларына дәүләт ярдәме чараларын камилләштерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Л.Н. Шәфигуллин, Р.Р. Гайзатуллин, М.Һ. Галиев | II квартал |
| 14 | «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (федераль законнарга туры китерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты | III квартал |
| 15 | «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (федераль законнарга туры китерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты | III квартал |
| 16 | «2025 елга Татарстан Республикасында хезмәт базары үзенчәлекләрен чагылдыра торган региональ коэффициентны билгеләү турында» Татарстан Республикасы законы проекты | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты | III квартал |
| 17 | «Авыл хуҗалыгын үстерү, авыл территорияләренең тотрыклы үсеше өлкәсендә дәүләт ярдәменең аерым мәсьәләләрен җайга салу турында» Татарстан Республикасы законы проекты (федераль законнарга туры китерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты | IV квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 18 | «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проекты | Татарстан Республикасы Рәисе | IV квартал |
| 19 | «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проекты (Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 61 статьясы нигезендә) | Татарстан Республикасы Рәисе | IV квартал |
| | **3. Социаль сәясәт** | | |
| 20 | «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына һәм «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннар белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (федераль законнарга туры китерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты | I квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 21 | «Халык сәнгать һөнәрләре һәм кәсепләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (федераль законнарга туры китерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты | II квартал |
| 22 | «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» Татарстан Республикасы законы проекты | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты | III квартал |
| 23 | «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасында гомуми белем бирү һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» Татарстан Республикасы законы проекты | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты | III квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **4. Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативалары** | | | |
| 24 | «Атмосфера һавасын саклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында (тискәре метеорологик шартларда атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгаруны киметү чаралары планнарын Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары белән килештерүне бетерү максатыннан, шулай ук тискәре метеорологик шартларда атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгаруны киметү чаралары планнары өчен хәбәр итү характерын кертү максатыннан) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.Г. Хәбибрахманов | I квартал |
| 25 | Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 265 статьясына үзгәреш кертү турында (урта һөнәри белем бирүче мәгариф оешмаларында укучылар тарафыннан һөнәр практикасы үтүнең аерым мәсьәләләрен җайга салу өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты | II квартал |